# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“10” ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 10 ноябрендә «“Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Иске Җогып авылында кечкенә күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) Иске Җогып авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алу;

“РИЗА” “КАРШЫ”

Сез, 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын, түбәндәге җирле сорауларны чишүгә юнәлтергә ризамы:

1) Иске Җогып авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алу;

“РИЗА” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 109 (бер йөз тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 64 (алтмыш дүрт) кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 64 (алтмыш дүрт) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. «“Сез 2023 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Иске Җогып авылында кечкенә күперне ремонтлау (материаллар сатып алу, эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Иске Җогып авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алу;

Сез, 2022 елдагы экономияләнгән үзара салым акчасын Иске Җогып авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алуга юнәлтергә ризамы"

мәсьәләсен кабул ителгән дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогып авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Иске Җогыпавылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.